Сабира Сталберг

# Филип хайван бакчасында



**Сабира Сталберг**

# Филип хайван бакчасында

**Фазилә Насретдин тәрҗемәсе**
**Мария Виитасало рәсемнәре**

1 җиңел тел

aybagar

Хельсинки 2022

**Җиңел тел дәрәҗәләре**
**Дәрәҗә 1: Иң җиңел**
Дәрәҗә 2: Җиңелрәк
Дәрәҗә 3: Җиңел

Tatar, Cyrillic script
1. басма / edition

Швед телендә / Original:
Sabira Stahlberg: *Filip i djurparken*
Тәрҗемә: Фазилә Насретдин
Translation: Fazile Nasretdin
Рәсемнәр / Illustrations: Maria Viitasalo

Эш төркеме: Альбина Самархан,
Камәр Яфай Ногманов

Мөхәррир: Лилия Дәүләт

© Сабира Сталберг, 2022
© Фазилә Насретдин, тәрҗемә, 2022
© Мария Виитасало, рәсемнәр, 2022

Айбагар ▸ aybagar.eu
Хельсинки / Helsinki 2022

ISBN 978-952-7334-81-2 (кәгазь китап)
ISBN 978-952-7334-82-9 (е-китап, PDF)

# Бүлем 1

Минем исемем Филип.
Мин акулаларны яратам.
Акулалар дөнья кадәр зур һәм куркыныч.
Аларның тешләре күп.
Аркаларында бер үткен канат бар.
Минемчә, акулалар шәп.

Мин үткен тешле хайваннарны яратам.
Күпме куркынычрак булса,
тагын да күбрәк яратам.

Без – әти, әни һәм мин бер
зур аквариумга барган идек.
Аквариумда диңгез балыкларының
күп төрләре бар һәм анда төрле
диңгез хайваннары да яши.

Яңа камерам белән бик күп
фоторәсемнәр төшергән идем.
Әле компьютерымда бик куркыныч
акулаларның шәп рәсемнәре бар.
Иң яратканнарым – юлбарыс акулалары.

Бибинур апам һәм София кузиным
әле бездә кунакта.

Софияның мәктәбендә яллар
һәм апа эшеннән ял көннәре алган.
Алар башка шәһәрдә торалар.
Җәен безгә кунакка килгәлиләр.
Ике атна торалар. Ике атна!
Ничек чыдарга!

Бибинур апага чыдый алмыйм,
шуның өчен аңа апа гына дип эндәшәм дә.
Ул беркайчан да кызык
нәрсәләр эшләргә рөхсәт итми.

Минем әнием дә вакыты-вакыты белән
ачулы һәм нервалы.
Ләкин ул апа кебек үк ачуымны китерми.
Агачка менгәндә, әни кычкыра:
‒ Филип, саклан!
Ләкин апа:
‒ Филип, шуннан ук төш.
Хуштан китәм! Бу нинди ахмаклык.

Бибинур апа бик ахмак кеше.
Аның эте тагын да ахмаграк.
Этнең исеме Бикбай.
Ул кечерүк кенә пудель,
исеме үзеннән озынрак.
Бикбайга Били дип эндәшәләр,
ләкин мин Җили дип исем бирдем.

Чөнки аның колаклары
йөгергәндә җилферди.

Апам Җилине бәбәй кебек карый.
Аны һәрьякка алып бара.
Төрле татлылар ашата.
Уйлап карачы, әгәр дә Җили
таза булса иде, дүртаяклы йонлы
казыга охшар иде.

Кузиным София бөтен
нәрсәне белә.
Софияга да чыдый алмыйм.
Ул мине надан дип уйлый.
Ләкин әни дә,
әти дә аны бик яраталар.

Әни әйтә:
– София бик сөйкемле.
Әдәпле дә, тыңлаучан да.
Әти әйтә:
– София акыллы.
Филип, сиңа аңардан
үрнәк алырга кирәк.

– Юк, рәхмәт – җавап бирәм.
– Ул тәкәббер. Мин кыланчык
кешеләрне яратмыйм.

# Бүлем 2

София турындагы фикерләрем белән
әти-әнине ышандыра алмадым.
Киресенчә. Әни әйтә:
– София сәләтле кыз.
Китаплар укый һәм дә бик батыр.
Әти өсти:
– Филип, сиңа күбрәк укырга кирәк.
Дәвамлы укып торсаң, зиһенең арта.
– Юк, рәхмәт, – җавап бирәм.
– Ай моннан караганда ничек еракта,
аны София белә, шик тә юк.
Ләкин мин айга барырга уйламыйм.
Мин акулаларны кулга
ияләштерергә телим.

– Акулалар ерткыч хайваннар.
Сине ашап куярлар, – әни әйтә.
– Менә шуның өчен.
Алар кешене дулкынландыралар.
Мине ашамыйлар. Мин аларны яратам.
Аны алар беләләр, – җавап бирәм.
Әти белән әни, икесе дә
авыр сулап башларын чайкыйлар.
– Беркөнне Филипкә акыл керер инде, –
әни әйтә.

– Шулай булсын инде, – әти өстәп куя.
Бүген мин апа һәм София белән
хайван бакчасына барырга тиеш.
Әти белән әни икесе дә эштә.
Әни әйтә, София хайван бакчасын
күрергә тели дип.
София бик хайваннар ярата.
Алар турында һаман сөйләп тора:
– Белдегезме, агач бакасы агачка менәлә,
– дип аңлата. – Тәмам Филип кебек.

София миңа мыскыллап карый.
Мин ачуланам.
– Мин зоопаркка барырга
уйламадым, – әйтәм.
– Анда күңелле, – әни әйтә.
– Син үрмәкүчләр яратасың бит.
– Куркыныч хайваннарны рәсемгә
төшерә аласың, – әти әйтә.
– Камераңны онытма, – искәртә.

Минемчә хайван бакчасы кызыксыз.
Анда кечкенә балалар гына йөри.
Мин аквариумга барыр идем.
Скатны яңадан рәсемгә төшерер идем.
Үткән мәртәбә төшергән
рәсемнәрем бик уңмады.
Скатның нәрсә икәнен беләсеңме?

Ул зур һәм җәйпәк балык.
Аның тәнендә энәләр бар.
Койрыгы озын һәм үткен.
Ул суда әкрен генә шуып йөзә.
Бик куркыныч һәм искиткеч матур да.
Аның кебек куркыныч затлар
хайван бакчасында юк.



# Бүлем 3

Бибинур апа пуделен
зоопаркка алып барырга тели.
– Юк. Били өйдә кала.
Хайван бакчасына этләр кертергә ярамый.
Рөхсәт ителми, – София әйтә.
– Бикбай көн буе ялгыз
тора алмый, – апа карыша.
– Ул куркырга мөмкин.
Беркайчан да ялгыз калганы юк.
– Әннә, эт өйдә кала, –
София бик кискен әйтә.

София әнисенә әннә дип эндәшә.
– София Эленора, – Бибинур апа
сүзен башлый, ләкин шуннан
ук дәшми кала.
Чөнки София белән сөйләшеп булмый.
Тышка чыкканда апа ишек
төбендә туктый.
Җилинең борынын үбә.
Ничә тапкыр үбә.

– Син әле акыллы тор.
Без тиз кире кайтырбыз, –
дип аңлата.

Җили өрә.
Нәни койрыгын селкетә.
Ападан котылдым дип шатлана,
уйлыйм.
– Ой, кояш эшләпәмне оныттым, –
апа баскычта сизә.
Ул бик еш оныта.
Яшел төсле салам эшләпәсен барып ала.
Эшләпә шәмәха бау һәм
сары розалар белән бизәлгән.
– Әле мин әзер, – шатланып әйтә дә,
эшләпәсен кия.

Хайван бакчасына без
автобус белән барабыз.
Тукталышта күп кеше басып тора.
Безгә карыйлар.

Апаның өстендә кызыл шакмаклы,
бигрәк ямьсез күлмәк.
Бик кычкырып сөйли.
Бөтен кеше сөйләгәнен ишетә.
Мин аның сөйләгәнен һич тә аңламыйм,
тыңламый гына торам.

Күзем апаның зур сумкасына төшә.
Чанта көмеш төсле,
кояшта ялтырап тора.

Кызык.
Кыймылдандымы?

Ниһаять, автобус килә.
Иң беренче булып Бибинур апа керә.
Чантасын идәнгә куя да,
янчыгыннан акча эзли.

– Вак акчамны кая куйдым? – исе китә.
Артыбызда озын чират –
балалар һәм олылар көтеп тора.
Һәммәсе зоопаркка барырга тели.

Балалар тынычсызланалар,
бер-берләрен төртешә башлыйлар.
Араларыннан бер малай
аркама төртеп ала да,
апаның чантасы өстенә егылам.

Чанта кузгала да,
чинау тавышы ишетелә.
Бу нәрсә…
дип уйларга да өлгермим,
шунда ук чантадан
Җили сикереп чыга!

# Бүлем 4

– Бикбай. Тиле малай! –
дип Бибинур апа кычкыра.
Пудель автобуска йөгереп керә.
Апа аның артыннан йөгерә.
Билетләребезне түләргә оныта.
Ләкин мин ападан
элегрәк өлгерәм.
Җилине автобусның уртасында тотам.

Ул шатланып өрә.
– Фу сиңа, тукта!
Болай качып
китәргә ярамый, –
Бибинур апа орыша.

Аннары Җилине кочаклый.
Шунда Софияны күрәм.
Ул барыбызның да юлын түләгән.
Билетләребез кулында.
Бик ачуланганга охшый.

– Әннә, син Били белән
өйгә кайтасың.
Без аны хайван бакчасына
алып бармыйбыз, – ачуланып әйтә.

Апа Җилинең борынын үбә.
Софияга исе дә китми.
– Алтыным, – әйтә.
– Күз нурым!
– Әннә, – София кисәтә.

Бибинур апа аңа:
– София Эленора, әле җитәр.
Без этне зоопаркка алып барабыз.
Һәм дә аның турында
артык бер сүз дә юк! –
ачуланып әйтә.

София ни булса әйтергә
дип авызын ача,
ә апа инде автобусның артына бара.
Җилине кочаклап
бер урындыкка утыра.

София автобуста алда утырып кала.
Ялгыз.
– Хайван бакчасында беркем
Билигә дикъкать итмәсә ярар иде,
ә итсә, проблема туа, –
София үз-үзенә мыгырдана.

– Филип, син кайда калдың?

Бире кил, – апа кычкыра да,
миңа көлеп кул изи.

Бибинур апа коточкыч кеше.
Әмма миңа аның
янына барырга кирәк.

Автобустан төшеп калыр идем.
Беркайчан да болай
оялганым юк иде.
Битләрем пешә дә кызара.
Апа берни сизми.
Лыгырдап кына тора.

Миңа һәм Җилигә сөйли
һәм дә бөтен автобус аша
Софияга да кычкыра.
Җилидән башка беркем
аны тыңламый.

Эт чанта эчендә утырган да,
кечкенә кара күзләрен
апага төбәгән.

Мин ни эшли алам соң?

# Бүлем 5

Ниһаять, автобустан төшәбез.
София зоопаркка керер өчен
билетләр ала.
Ачулы икәнен сизәм.
Миңа калса, Бибинур апа моны сизми.
Берни булмагандай Софияга сөйли.

София кергәндә апаның чантасын яба да,
кырт кисеп әйтә:
– Били, әле сиңа әкрен торырга кирәк,
тының да чыкмасын.
Болай сине туп-туры өйгә озатам.

Әле хайван бакчасының
керешендә карта карыйбыз.
– Мин иң башта кошлар карарга телим, –
София әйтә.
Бармагы белән кош рәсемен күрсәтә.
– Син ничек телисең, – апа җавап бирә.
– София карар кылсын.
Аннары яшел салам эшләпәсен турайта.

Чантада Җили кыймылдана.
Апа чантасын ача.
Җили чинап җибәрә.

Аның башы гына күренә.
Ул чанта эчендә ябылып
торырга яратмый.

Бер бик зур читлек янында туктыйбыз.
Анда бер агачка чуар кош кунган.
Эт өрә башлый. Кош кузгалмый да.
– Бу нинди кош? Бөркет микән? –
апа сорый.
– Мәче башлы ябалак, –
София җавап бирә.
– Аның башында
мөгез кебек ике чугы бар.

– Бик кызыклыга охшый, –
Бибинур апа әйтә.
– Ябалаклар артка күрер өчен
башларын әйләндерә алалар, –
София аңлата.
– Бик күп беләсең, –
апа авыр сулап ала да,
эшләпәсен турайтып куя.

Җилкәмне сикертеп алам.
Ябалаклар куркыныч түгел.
Алар утырып күзәтеп кенә торалар.
Әкрен утырып тора торган
хайваннарны мин яратмыйм.

Хәрәкәтле хайваннарны яратам.
Бигрәк тә йөзә торганнарны.
Икенче, тагын да зуррак,
читлек янында туктыйбыз.

– Болар диңгез бөркетләре, –
София әйтә.
– Бер бөркетнең авырлыгы
җиде кило тарта.
Канатара иңлеге якынча ике метр.
Алар күбесенчә балык ашыйлар.
Ояларының авырлыгы 500 килодан артык.

Бибинур апа читлек янына бара.
– Бөркетләр кайда? – кызыксынып сорый.
Нәкъ шул вакытта бер зур диңгез бөркете
очып якыннан узып китә.
Коточкыч һәм матур бөркет!

Тын да алмыйм.
Бөркетнең томшыгы үткен,
тырнаклары озын, көрән төсле.
Камерамны чыгарам.
Фотога төшерергә телим,
ләкин ул бик тиз очып китә.
Ике тонык рәсем генә төшереп өлгерәм.

Әнә, тагын килә!

# Бүлем 6

Ой! Бөркетнең икенче канаты
чак кына апага тими.
– Ярдәм, – Бибинур апа кычкыра.
Апаның салам эшләпәсен
җил алып китә дә, чантасы җиргә төшә.

Җили каты өрә.
Чантадан чыгарга тырыша,
ләкин кача алмый.
Чантаның зиппере кысылып калган.
Апа бер-ике адым артка атлый.
Аркасы артында белдерү тактасы тора.
Аны сизми дә, туп-туры шунда бәрелә.
Башын тактага суга да:
– Ай, – дип кычкырып җибәрә.

Бик көлке күренеш. Мин көлә башлыйм.
Апаны тиз-тиз фотога төшерәм.
Тактада:
Читлек янына барырга ярамый.
Бөркетләр куркыныч дип язылган.

София бик ачуланган:
– Ыржайма миңа! – пышкыра.
– Камераңны монда бир!

Мин шуннан ук көлүемнән туктыйм.
София камерамны кулымнан
тартып алырга тырыша,
әмма мин тизрәк качарга өлгерәм.
Миңа ямьсез карый.
Аннары әйләнә дә,
апаның эшләпәсен алырга йөгерә.

Апа чантасын җирдән күтәрә,
Җили чанта эчендә.
Эшләпәсен кия дә,
каты көлеп җибәрә.
– Бак, ничек кызык хәл булды, – әйтә.

Бибинур апа берни булмаганга салыша.
Әмма София көлми.
Аның ике бите ап-ак.
София минем көлгәнем һәм рәсем
төшергәнем өчен бик ачулы.
Бераз куркынам.
Аны мин беркайчан да мондый ачулы
күргәнем юк иде.

– Рәсемне камерадан чыгара алам, –
әйтәм. София җавап бирми.
Миңа таба карамый да.
Иренен тешләп,
аякларына карап каткан.

– Филип, әле синең рәтең, –
апа йомшак кына әйтә.
– Кая барабыз? Син сайла.

– Мин куркыныч хайваннар
карарга телим.
Ябалаклар да бөркетләр
кызыксыз, – җавап бирәм.

– Еланнар, – апа тәкъдим итә.
– Син питоннар күрергә
телисең, әлбәттә.
– Чыннан да куркынычларны
һәм дә зәһәрлеләр булсын, –
җавап бирәм.
– Башкасы кызыксыз.



# Бүлем 7

Әле без бер зур пыяла тәрәзәле
бина алдында тукталабыз.
Тәрәзә артында кошлар һәм
сәер яфраклы үсемлекләр күрәбез.

– Без кечкенә алтын төймәм белән
тышта калабыз, – апа әйтә.
– Кояш бик матур балкый, – дип
ялгый да этен кысып кочаклый.
– Эскәмиядә утырып бераз вакыт
рәхәтләнәбез.

Бинага кергәндә София әле
дә ачулыга охшый.
Мин йомшак кына сорарга тырышам:
– Ник әниең безнең белән еланнар һәм
үрмәкүчләр карарга керми?

София озак җавап бирми тора.
Аннары әйтә:
– Әннә еланнардан курка.
Үрмәкүчләрне дә күрә алмый.

– Ахмаклык, – әйтәм.
– Син ахмак, – София пышкырып куя.

– Син яратасың дип башкаларга да
барлык хайваннарны яратырга
кирәкми бит.

Үзең ахмак, ялгыз уйланам.
Мин барлык хайваннарны яратам бит.
Еланнар, акулалар кебек үк,
шәп булмасалар да,
алар да искиткеч кызык.
Әмма мин берни әйтмим.

Мин Софияга уйларымны аңлатсам,
ул тагын да ачулырак була.
Чаян янында туктыйбыз.
Ул байтак кечкенә.
Койрыгы калкып тора да,
башы өстенә бераз бөгелә.
Камерамны чыгарам.
Рәсем шәп уңа.

– Чаяннар алга, артка һәм
ян якка йөгерәлә, белдеңме? –
София эреләнеп сорый.
– Әлбәттә, беләм, – җавап бирәм.
– Аның койрыгындагы энәсе
генә зәһәрле, белдеңме? –
София дәвам итә.
– Беләм, – җавап кайтарам.

– Аларның ике кайчы сыман кыскычы
һәм дүрт пар сыйраклары бар,
анысын белдеңме, – София сорый.

Анысын мин белмим,
ләкин белгән кебек кыланам.
София тагын да тәкәбберрәк
булсын дип теләмим.

– Алар җылыны ярataлар, – София аңлата.
– Чаяннарга иң азыннан
20 градус җылылык кирәк.
Алар көндез йоклыйлар, белдеңме?
Күбесенчә төнен аулыйлар.
Үземне ахмак тоям.
Боларны барысын да миңа
белергә тиеш иде бит.
Чаяннар куркыныч – мин бит
куркыныч хайваннар турында
барысын да беләм.
Һәрхәлдә белгәнгә салышам.

– Чаянны аквариумда тотып
булыр иде, әйтәм.
– Үз чаяның булса иде,
ничек күңелле булыр иде.
Шунда аркабыз артында аяк
тавышлары ишетелә.

# Бүлем 8

Бибинур апа килә икән.
Ул Җилине кочагына алган.
Тирә-ягын күрми дә.
– Анда икән сез, – пуфылдый.
– Искәрмәстән яңгыр ява башлады.
Ышык урын табарга кирәк булды.

Апа юешләнгән.
Җили тунын кагына.
Өстебезгә су тамчылары чәчри.
– Филип чаян тели, – София җиткерә.
– Җирәнгеч! – апа каты кычкырып
җибәрә. – Әниең ни әйтер?

Мин Софияга кырын гына карап алам.
Ул әле миннән үч ала.
Бибинур апа миңа каныга инде,
ә кич белән әни мине әрләр.
Апа барысын да әнигә сөйли.
София көлеп әнисенә әйтә:
– Әннә, сиңа чәчеңне киптерергә кирәк.
Бәдрәф әнә алдарак уң якта, – күрсәтә.
– Сез дә киләсез. Монда, куркыныч
хайваннар арасында сезне ялгыз
калдыра алмыйм, – дип нык кына әйтә.

– Мин еланнар багарга телим.
Һәрхәлдә миңа аларны
фотога төшерегә кирәк, – әйтәм.
София әнисенә:
– Безне маймыллар
янында көт, – дип әйтә.

Мин Софияны аңламыйм.
Башта миңа ачулы да,
аннары булыша.
Нәрсә уйлый икән?

Сорарга телим, әмма куркам.
София пыялага борынын төртеп,
кечкенә кәлтәгә карап тора.

– Геккон. Бу кәлтә геккон, –
София аңлата.
– Аның аякларында вак йоннар бар.
Алар ярдәмендә ул диварларга да
түшәмнәргә менәлә.
Ул бөҗәкләр белән туклана.
Файдалы хайван.
Әйдә!
Әле еланнар янына барабыз, –
дип София чакыра.

# Бүлем 9

Анаконда яткан, ярты гәүдәсе суда,
икенче яртысы комда.
Арабызда пыяла дивар гына.
Еланның башын да, койрыгын да
күрә алмыйм, уртасын гына.

– Бу яшел анаконда. –
София аңлата башлый.
– Ул ун метр озын һәм
200 килодан күбрәк тарта.
Анаконда дөньяның иң зур һәм
иң авыр еланы дип санала.

– Дөнья кадәр зәһәрледер дә, – әйтәм.
– Һич тә түгел. – София каршы килә.
– Ул тешли, ләкин зәһәрле түгел.
Эләктергән табышын анаконда буа.
Крокодилны да буа ала.
– Кызык. Аны ул ничек эшли? – сорыйм.
– Тоткан табышын гәүдәсе белән
урап ала да каты гына буа. Әмма,
Филип, сиңа куркырга кирәкми.
Син тәмле түгел. Кетчуп белән дә.
– Ха-ха, бик кызык, – ачуланып
җавап бирәм.

# Бүлем 10

Бибинур апа маймыллар бинасы янында,
бер читлек алдында Җили белән
безне көтә. Җилине бауга бәйләгән.
Читлектә бер маймыл яши.

Читлекнең рәшәткәләре арасыннан
кулны кертеп була.
Аннан маймыл да кулын суза ала,
ләкин үзе тышка чыга алмый.

Маймыл кечкенә күзләре белән
безне күзәтә.
Ул бер агач ботагына утырган да,
аркасын кашып тора.
Зарарсызга охшый.

– Кызыксыз, – мыгырданам.
Читлек рәшәткәсе янына барам да,
камерамны чыгарам.
– Филип, бик якынга барма.
Маймыл эшләпәмне алырга
тырышты инде, – апа кисәтә.

Белдерү тактасындагы язуны укыйм:
Вакытлыча читлек.

Саклан!
Маймыл урларга ярата.
Дулкынландыра торган хәл!

Маймылны рәсемгә төшерергә әзерләнәм.
Камераны читлекнең эчке
ягына кертәм дә,
бер рәсем төшерәм.
Тагын бер кат чиртәм.
Өченче рәсемне төшергәндә
маймыл сикереп төшә дә,
камерамны кулымнан тартып ала.

Апа илерә, Җили өрә.
Эт читлеккә керергә тырыша,
ләкин апа аны бавыннан тартып кычкыра:
– Ул пычрак маймыл.
Бетләре дә бардыр.
Били! Якынына барма.
Тиз генә пудельне чантасына тыга.
Эт өрүеннән туктый.

Мин маймылга бик каты кызам.
Читлек рәшәткәсен ике кулым
белән тотып даңгырдатып селкетәм.

Маймылга ямьсез сүзләр кычкырам.
Бәхетемә, апа миңа дикъкать итми.

Ямьсез сүзләр сөйләргә әни
миңа рөхсәт бирми бит.
София гына тыныч.
Миңа әйтә:
– Тукта. Сүгенеп торма.
Файдасы юк.
Маймыл барыбер сөйләвеңне аңламый.

Ләкин мин Софияны тыңламыйм.
Маймыл камерамны вата инде,
дип куркам.
Камерамда бик күп
матур рәсемнәр бар.

Маймыл ботакка утырып,
камерам белән уйный.
Камерамны тешли.
Мин кычкырам:
– Тукта, идиот.

– Син үзең идиот, –
София мыгырдый.
– Маймыл дөресен әйткәндә маракатт.
Камераны ашап була дип уйлый.

Маймыл камераны идәнгә бәрә.
Бөтен гәүдәм суынып киткәнне сизәм.

# Бүлем 11

Маймыл сикереп төшә дә,
камераны күтәреп ала.
Аны тырный, агачка суга.
Төймәсенә кат-кат баса.

Камерам ватылды инде, шик тә юк.
– Камераны кокос чикләвеге дип
уйлый яки башка бер каты
чикләвек, – София хыхылдый.
– Барыбер, – Софияның сүзен бүләм.
– Камерамны гына телим, әйтәм.

– София Эленора, карауч‌ы
табарга кирәк, – Бибинур апа
берни эшләргә дә белмичә кычкыра.
– Син генә бар, – София җавап бирә.

Апа чантасын җиргә куя, эчендә Җили.
Аннары маймыллар йортыннан
йөгереп чыгып китә.
– Филип, хайван бакчасының харитасы
синдә бит? – София сорый.
– Аны миңа бир.
– Һарита белән маймыл арасында нинди
бәйләнеш бар икән, дип гаҗәпләнәм.

– Бир аны монда, –
София пышкырып әйтә.
Нигә аңарга харита кирәк,
мин аңламыйм, алай булса да бирәм.
София кулын рәшәткә арасыннан
кертә дә, хаританы селки башлый.

Маймыл камера чәйнәвеннән туктый.
Якынрак килә.
Һарита аны кызыксындыра кебек.

– Камераны монда бир, –
маймылга кычкырам.
– Әкрен тор, – София кисәтә.
Маймыл шунда куркынып өлгерә дә,
агачка сикереп кача.

София хаританы тагын селки:
– Монда кил, – йомшак кына эндәшә.
Маймыл сакланып кына кулын
харитага таба суза.
– Камераны миңа бир, –
София түбән тавыш белән әйтә.
Маймыл башын кырын сала.
Уйлап утыра да, колак артын кашып ала.
Юк, ул теләми.
Ул агач ботагында утырып кына тора.
Безгә шикләнеп карап тора.

Камерамны беркайчан да
ала алмыйм инде.
Юньсез маймыл минем шәп камерамны
үзендә тотарга тели.
Мин маймылларны яратмыйм.

‒ Әннәнең чантасында бер
кап чикләвек бар, ‒ София пышылдый.
Апаның чантасын ала дә казына.
Чикләвек юк.
Җили маймылны тагын күрә дә өрә.
‒ Тукта! ‒ София әйтә.
‒ Болай тавышларга ярамый.
Кем булса сине күрер дә,
безне өйгә озатыр.

Җили маймылны күрмәсен дип
София чанта зипперен яба.
‒ Кесәмдә лакрица бар,
ләкин ул маймылларга яхшы түгел.
Яшелчә, чикләвек яки җимеш кирәк, ‒
София үзалдына сөйләнә.

‒ Хайваннарны ашатырга ярамый.
Белдерү тактасында
шулай язылган, ‒ әйтәм.
‒ Димәк, камераңны беркайчан
да алалмыйсың, ‒ София әйтә.

# Бүлем 12

Җимеш? Капылт итеп исемә төште.
Миндә бер җимеш бар бит.
Иртә белән, өйдән киткәндә,
әни биштәремә бер банан салган иде.
Бананны чыгарам да, Софияга бирәм.
Ул аны бераз арчый да читлек эченә суза.

– Менә, бананны тәмләп кара,
телеңне йотарсың, – маймылга әйтә.

Маймыл агачтан сикереп төшә дә,
бананны алырга тырыша.
София кулын тиз генә кире тарта.
– Юк, – елмаеп әйтә.
– Башта камераны миңа бир.
Аннары сиңа бананны бирермен.

Маймыл аркасын кашый да уйлана.
Бер кулы белән читлек рәшәткәсеннән
тотып тора, икенче кулында камера.
Банан аны күбрәк кызыксындыра.
Камераны кулыннан ычкындыра да,
ул идәнгә читлек рәшәткәсе янына төшә.

– Ал аны, – София миңа пышылдый.

Тиз үк кенә күтәреп алам.
Тагын камера белән
уйный башламасын гына.

Маймыл бананны ала да,
сикереп агачына кайта.
Анда бананны арчый да,
ашап куя.



# Бүлем 13

София камераны кулымнан ала.
Төймәсенә баса. Камера выжылдый.
Маймыл утырган, ашый.
Аны рәсемгә төшерә.
– Камерада теш эзләре бар,
ләкин эшли, – София белгертә.

Апа хайван карауучысы
белән эчкә атыла да:
– Маймыл тегендә.
Ул Филипнең камерасын алды, –
дип кычкырып әйтә.
– Камера миндә, – күтәреп күрсәтәм.
Камерамны кире алалдым дип
рәхәтләнеп киттем һәм шатландым.
– Ватылмаган. Өстендә теш эзләре генә
бар, – ялгап җибәрәм.

Кемнең камерасында теш
эзләре бар икән!
Шатлыгымнан көләсем килә.
Беркемнең дә камерасында
маймылның теш эзләре юк!
– Бөтен зоопаркны йөгереп әйләндем, –
апа пуфылдый.

– Тынычланыгыз, – караучы әйтә.
– Мәсьәләне ничек хәл иттегез,
аны аңлатыгыз.
София банан турында аңлата.
Аның банан ашатканы өчен абый
ачуланыр дип уйлыйм.
Юк, ул көлә генә.

– Оста, тапкыр икәнсең, – абый әйтә.
– Син хайваннар турында күп
беләсең, күрәм?
– Мин хайваннар яратам.
Хайваннардан кызыграк нәрсә юк.
Мин хайваннар табибы булырга телим,
ветеринар, – София дәртләнеп аңлата.
– Монда эшкә рахим ит. Безгә яхшы
ветеринарлар кирәк, – караучы әйтә.

Бибинур апа сүзне бүлә:
– София Эленора әле кечкенә.
Аңа әүвәл мәктәбен тәмамларга,
аннары университетта укуын
дәвам итәргә кирәк.
– Мин беләм, – София үзсүзләнә.
– Ветеринәр булырга уйлыйм.

– Әйбәт. Аңлашылды, – караучы әйтә.
Софияга кул бирә дә, юлын дәвам итә.

София бик горур күренә.
Мин дә тәэсирләнәм,
әмма ләкин хисләремне күрсәтмим.
София хайваннар турында
миннән шактый күбрәк белә.

Кузиным бик белемле
Мин аңа горурланам.
– Рәхмәт. Камерамны
коткарганың өчен рәхмәт, –
мыгырданып Софияга әйтәм.
– Берни түгел, – София җавап бирә.

Әле инде Софияның чыннан да
күп белгәнен аңлыйм.
Миңа әлдә күп өйрәнергә кирәк.
Аны да аңлыйм.

Камерамны яхшырак сакларга кирәк.
Маймыл аны эләктерде,
ул минем үз хатам иде.

Апа Җилине чантадан
алып чыгарып җибәрә.
Ул маймылга өрә башлый.

Маймыл банан кабыгын
тота да Җилинең өстенә бәрә.

# Бүлем 14

– Әле мин бер чашка каһвә
эчәр идем, – Бибинур апа әйтә.
– Аның белән генә нерваларым
тынычлана. Бөтенләй беттем.
– Куркынгач, һаман да әннәмнең
ашыйсы килә, – София аңлата.
– Минем дә әниемнең ачуы килгәндә яки
куркынса ашыйсы килә, – әйтәм.

Искәрмәстән София елмая.
Беренче тапкыр аның елмайганын күрәм.
Елмайганда ул чыннан да сөйкемле.
– Мин вафли телим.
Һәм дә туңдырма белән, –
София кычкырып җибәрә.
– Мин дә телим.
Мин шоколад белән, – шатланып әйтәм.

Хайван бакчасының кафесына барабыз.
Апа зур чашка каһвә белән
кайнатмалы күмәч ала да:
– Миңа әздән бер литр каһвә кирәк.
Болай хуштан китәм, – дип аңлата.
– Юкны сөйләмә! – София мыгырдый.
– Син бик җиңел хуштан китмисең.

Кафеның ишек алдындагы
бер өстәл артына барып утырышабыз.
Анда беркем дә юк дип әйтеп була.

София белән вафлиларыбызны
ашап куябыз, ләкин апа
ашыкмыйча гына каһвәсен эчә.
Җили апаның аяк төбендә яткан,
борынын тәпиләре өстенә куйган.
Арыганга охшый.

Бибинур апа муенчагын алып куя да:
– Әле ял итә аласың, – әйтә.
– Кара нинди матур кошлар, –
бармагы белән күрсәтә.
– Койрыгында озын каурыйлар
булганы иң матуры.
Ул фазандыр?

– Әннә, ул кош тәвис, – София әйтә.
Тәвис томшыгын ача да,
ямьсез тавыш белән кычкырып җибәрә.
Апа сискәнеп китә дә:
– Ой, ничек ямьсез кычкыра.
Өрәк тавышы кебек.
Кош ничек болай шомлы кычкыра ала?
Бер акчарлак һавадан атылып төшә.
Ул апаның күмәчен урларга тырыша.

– Күл акчарлагы, – София әйтә.
– Аның башы кара.
Бак! Әнә, тагын килә, күрсәтә.
– Яман кошлар, – апа кычкыра да,
куллары белән кошны куа.
Акчарлак очып китә.

Яныбыздагы өстәлдә каргалар һәм
чыпчыклар сикеренеп тора.
Анда кемдер ашаган да,
икмәк валчыклары өстәлдә калган.
– Карагыз, каргалар нинди матур кошлар,
– София әйтә.
Камерамны ала да,
әкрен генә кошлар янына бара.
Җили аңа иярә.
Ул эскәмия өстенә сикерә дә, өрә.
Кошлар очып үз юлларына китәләр.

– Куркытырга кирәкме иде? –
София сорый. Җили койрыгын
җилфердәтә. Бибинур апа әйтә:
– Зиһенле эт.
Кошлар һәрьякны пычраталар гына.
Туйдырганчы кычкыралар да.

Искәрмәстән кафедан эчтән тавыш
ишетелә.

# Бүлем 15

Кафедан халык йөгереп чыга.
Иң беренче булып
озын чәчле кыз чыга.
Әллә нинди кечкенә
хайван безне
сикереп узып китә.

Нәрсә икәнен күрергә
өлгермим, ләкин София белә:
– Мангуст, –
дип дәртләнеп аңлата.
Әле мин дә аны күрәм.
Ул көрән төсле, зур ас сыман.
Койрыгы калын һәм озын.

Җили аның артыннан атылып китә.
Аның кыска аяклары җирдә дөберди.
– Тукта, – апа кычкыра.
Озын чәчле кыз һәм
бер-ике караучы
таудан аска таба йөгерәләр.
Алар мангустның
безне узгып киткәнен
сизеп өлгермиләр.
Башка якка баралар инде.

– Тиз генә, – София кычкыра.
– Җилине тотып бәйләргә кирәк.
Ул мангустны тешләп
үтерергә мөмкин.
Филип син уңга кит,
мин сулга китәм.

– София Эленора, юк, –
апа кисәтә башлый.
Без аны ишетмибез.
Әнә, Җили белән мангуст.
Юк, тагын югалдылар.

– Тукта, Җили, – кычкырам.
– Монда кил!

Икесе дә югалдылар.
Тын алырга туктыйм.
Мин кая килдем икән?

# Бүлем 16

Бередә зур, биек,
пыяла диварлы читлекләр.
Өсләре ачык.
Димәк, кошлар өчен түгел.
Кошларныкы түбәле була.
Кая таба барырга икән дип
уйланып торам.
Ике юл бар.
Кайсын сайларга?

Җилинең өргәнен ишетмим инде.
Ул бик еракта.
Уңга китимме, сулгамы?

Шунда уйланып торганда,
күзем бик кызык нәрсәгә төшә.
Бер читлектә, җирдә,
нидидер ак нәрсә ята.
Зур тирегә охшый.
Тире кыймылдана.
Авызы ачыла.
Зур, ачык, кызыл тамагын һәм
ике үткен алгы тешен күреп алам.

Ой! Тире дөнья кадәрле зур мәче икән.

Әкрен генә яткан урыныннан тора.
Тәпиләре зур.
Койрыгы бик озын.
Койрык очында кара чук.
Мәче авызын тагын да ача.
Мин дә иснәмичә тора алмыйм.

Үз-үземә әйтәм:
– Филип, сиңа әле йокларга ярамый.
Җилине табарга кирәк.
Ул мангустны тешләп үтерергә
өлгермәсен генә.
Читлек янында белдерү.
Кызыксынып карыйм. Элегрәк
мондый мәче күргәнем юк иде.

Белдерү тактасында язылган: Ак барс.
Мәче бөтенләй ак түгел икән.
Тунында кара таплар бар.
Әле киерелә дә, читлектә
әйләнеп йөри башлый.
Әкрен һәм йомшак тәпили.
Инде ямьле һәм зифа буйлы!
Минем мондый нәфислекне
беркайчан да күргәнем юк иде.

– Син искиткеч матур, – ак барска әйтәм.
Камераны чыгарам.

Әле! Ак барс нәкъ алдыма баскан.
Рәсемгә төшергәндә,
камера уты өрелеп ала.
Флэшны сүндерергә онытканмын.
Ак барс туктый.
Яшькелт күзләре белән мине күзәтә.
Кузгалмый, ләкин мырылдый.
Куркытыр өчен койрыгын селкетә.

Ак барс куркыныч.
Мин аны яратам да,
бераз аңардан куркам да.
Уйлап карачы, ул кеше ашаса!
Шөкер, читлекнең
диварлары пыяладан.

‒ Акыллы мәче.
Ачуланма.
Флэш кынә иде бит, ‒ әйтәм.

Ак барс тагын мырылдый да,
миңа аркасы белән борыла.
Кулларым калтырый.
Кинәт Җилинең өргәнен ишетәм.

# Бүлем 17

Камерамны кесәмә салам да,
өргән тавышка таба йөгерәм.
Тавыш каян килә икән соң?

Әле Җилине күрәм.
Ул бер читлек алдында котырынып өрә.
Читлек янына барам да,
селәүсенгә өрә икән дип күрәм.

Селәүсен ак барска караганда кечкенәрәк.
Койрыгы да бик кыска, өзек кенә.
Сакланып Җили янына барам.
Миңа бит аны тотарга кирәк.

Әле тота алмасам, беркайчан
да тота алмыйм!
Эшем уңмый.
Ул бик оста кача.
– Бире кил, – Җилигә кычкырам.
Мине тыңламый.
Мин якында булганны
күрмәгәнгә салыша.

Селәүсен чи ит ашый.
Җили чи ит исен сизә торгандыр.

Шуның өчен котырынган.
Ачыккандыр да инде.
Берничә тиз адым атлыйм да,
җили өстенә ташланам.
Ул сикереп китә дә,
мин лап итеп эчем өстенә
егылып төшәм.

Җили мыскыллап көлгән кебек өрә.
Аягүрә торам.
Сул тезем авырта.
Аны бая ташка бәрдем бит.
Йөгергәндә аксыйм.

Җили мине нык кына ачулатты.
Тагын тегендә!
Арысланнар читлеге алдында
мангустны куа.
Мин алар турысына җиткәч үк,
икесе дә югала.

Мин арысланнарны яратам.
Алар куркыныч.
Аларны рәсемгә төшерергә телим дә,
вакыт юк.

Җили кайдадыр еракта котырынып өрә.
София андадыр.

Җилинең бавы да аңарда,
ул этне тотсын.
– София, – кычкырам.

Җавап юк.

Мин япа-ялгыз.
Юк, мин ялгыз түгел икән.

Мангуст кинәт каршыма
йөгереп чыга.
Ул әллә нәрсәне куа.

Җилине түгел.
Пудель кайда соң?
Беркайда да күренми.

Мангуст нәрсәне куа?

# Бүлем 18

Әллә нинди озын колаклы,
көрән төсле, сикерә торган зат.
Йорт куяны, канин икән!
Ул туп-туры миңа таба килә.
Бик каты куркынган.

Мин нишлим?
Тиз генә уйлап карыйм.
Куянны мангусттан коткарырга кирәк.
Бер кулым белән куянны тотсам,
икенчесе белән мангустны тотармын.

Кулларымны ачып,
куянга каршы йөгерәм.
Ул качарга тырыша.
Бәхетемә, аны тота алам.
Тиз генә куянны кочаклап күтәрәм.
Ул тотканны яратмый.

Арткы тәпиләре белән тибенә.
Кечкенә булса да, көчле икән.
Алгы тәпиләре белән күкрәгемә кага.
Кулымнан котылырга тырыша.
Колаклары яссыланып,
аркасына сыланган.

Мангуст минем тирәмдә биеп тора.
Пышылдый да, сикеренә.
Әле күрәм, ул көрән белән ак төсле.
Мангуст та, дөресен әйткәндә,
байтак сөйкемле.
Борыны очлы.

Әле мангуст куянны тешләргә тырыша,
әмма куян урынына мине тешли.
Үткен тешләреннән
беләгемә яра кала.
Ул авырта, каный башлый.
– Ай, – кычкырам.
Куян кулымнан ычкына.

Җиргә сикереп төшә дә, мангуст
артыннан чаба.
Куянны тагын тотарга кирәк.
Болай аның җаны куркыныч астында.
Мангуст белән куян өчен ярышабыз.
Мангуст куянны тотам дигәндә,
мин эләктереп алам.

– Тукта, шаулама, –
мангустка кычкырам.
Мангуст балтырмны тешли.
Миңа Софияны яки башка берәүне
табарга кирәк.

Кем мангустны тота ала?
Бер үк вакытта куянны
коткара һәм дә мангустны тота
алмыйм мин.
Миңа ярдәм кирәк.

Йөгерә башлыйм.
Кайсы якка йөгерергә белмим.
Еракта алдарак тавышлар ишетәм.
Кемдер кычкыра.
Анда таба көчемнән килгән
кадәр тиз йөгерәм.

Мангуст артымнан килә дә,
чәлтеремне чеметеп ала.
Мин абынып китәм.
Ничек тә аңардан котылалмыйм.
Әле инде тубыгымны дә тешли.

Кайда бөтен кешеләр?
Нигә һәрьяк тынды?

Куян кочагымда тавышсыз тора.
Мин аптырап калам.

Үлдеме?
Кысып үтердемме?

# Бүлем 19

Куянны аркасыннан сыйпыйм.
Көчкә аягүрә тора алам.
Кинәт елыйсым килә.
– Акыллым, үлмә, – мыгырданам.

Аннары куянның
йөрәк кагышын тоям.
Үлмәгән.
Яши, ләкин бик каты куркынган.
Шуның өчен тып-тын тора.
Кара күзләрен йомгалап тора.
Сөйкемле.
Маңгай чәче бар.
Бер колагы бераз ертылган.
Әле йөрәге әкренрәк суга.
Артык курыкмый.
Яки бик курка.

Йөрәге туктарга тора?

Мангуст тагын куянны тешләргә тырыша.
Ул еракка сикереп китә.
Куянны коткарырга кирәк.
Ничек булдыра алам икән?
Бераз гына ачык калган ишек күрәм.

Шуннан йөгереп кереп,
ишекне ябып куйсам.
Ләкин бер мәсьәлә бар.
Ничек керергә?
Мангуст артымнан керәлә.

Белмим, әмма тырышырга кирәк.
Һәм дә тиз булдырырга кирәк.
Ишек янына җиткәч,
куян эчемә тибенә дә,
кулымнан котылып китә.
Ишектән атылып эчкә керә.

Оста куян!
Эчтә куркырга кирәкми.
Мангуст табанымны тешләп тора.
Ул куян артыннан җитәргә тырыша.
Ишекне калган көчем белән,
мангустның борыны алдында,
шап итеп каты ябам.

Мангуст тышкы якта кала.
Ишек рәшәткәсе аркылы
керергә тырыша,
ләкин сыймый.
Ямьсез тавышлар чыгара.
Булдырдым.
Куянны коткардым!

Тирән генә сулап алам.
Бөтен гәүдәм калтырана.
Беләгем каный.
Канны туктатыр өчен
кулъяулык кирәк.
Кесәмдә казынам.
Күлмәгем кан белән буяла.
Кесәмдә кулъяулык юк.

Һаман шулай!

Биштәрем кайда?

Әле миңа биштәрем кирәк,
ләкин ул апам янында кафеда калды.

Әни биштәремә һаман бер пакет
кәгазь кулъяулыклар куя.

Һәм дә без әле кайда?

# Бүлем 20

Күлмәгемдәге канны
сөртеп алам.
Әни ачулана инде, ләкин
әле башка берни дә
эшли алмыйм.
Канны туктатырга кирәк.
Беләгемне гәүдәмә каршы кысам.
Күлмәгемнең җиңе җылына
да дымлана.

Нигә борыныма бик сасы ис бәрелә?
Әле генә сизәм, мин читлек эчендә икән.
Бу читлек артында тагын
бер зуррак читлек бар.

‒ Филип, әле сиңа уйларга ярамый.
Уйласаң, куркасың гына, ‒
каты тавышка үзалдыма сөйләнәм.

Ләкин миңа уйларга кирәк.
Ишек ачык иде.
Димәк, бу кечкенә читлек
буш булырга тиеш.
Бәлки дә монда торучы хайван
качып киткәндер.

Бу мангустның читлегеме икән?

Юк, исе башка.
Мангусттан мондый ис килми.
Җирдә зуррак хайванның эзләре бар.

Кайсы хайванның эзләре икән?
Курка башлыйм.
Тирә-ягыма да карарга куркам.
Нинди генә хайван була ала.
Эзләр зур мәче
хайванныкына охшый.

Уйлап кара,
әгәр дә ак барс булса?



# Бүлем 21

Читлек эчендә тору яман.
Уйлап кара, беркайчан да
моннан чыга алмасам?
Уйлап кара, беркем дә мине тапмаса?
Хайван мине ашап куйса.
Паникага биреләм,
күңелем болгана башлый.

– Ярдәм, – кычкырам. – Ярдәм!
Кем дә мине ишетми.
Мангуст та күренми.

Сакланып кына ишекне
ачарга тырышам. Ишек бикләнгән.
Бередә хайваннар бөтен гомерләрен
рәшәткә артында яшиләр.
Һәркөн халык күбәүләп килеп
аларны күзәтеп йөри.

Һәммәсе рәсемгә төшерәләр,
бармаклары белән күрсәтеп торалар.
Әле мине кем дә карап тормый.
Барысы да карап торганда
ничек тоела икән,
күз алдыма китерәм дә уйланам.

Ямандыр. Ишекне даңгырдатам.
Кузгалмый да. Мангуст эчкә керәлми,
ә мин тышка чыгалмыйм.
Куян кайда?

Ул җиргә тишек казый башлаган.
Читлектән чыгарга тели.
Әгәр дә ишек астыннан үзенә
юл казып чыгарса,
мангуст аны тота алыр микән?
Ул, шик тә юк, якындадыр.
Ишек янында саклап торадыр.
Куянның сикереп чыкканын
гына көтеп торадыр.

Мин куянны күтәреп кочагыма алырга
тырышам, әмма ул кача.
Колагыннан эләктерәм.
Колаклары бик нәзеккә охшый,
әмма тиресе нык, ертылмый.
Куянны кочагыма күтәрәм дә,
күкрәгемә кысам.
Читлектән качмасын дип
аны нык тотарга кирәк.
Куян әкрен тора,
тавышларга да тырышмый.
Башын култыгыма качыра.
Мин дә качарга теләр идем.

Куянны тотып торганда,
үземне рәхат хис итәм.
– Син яхшы дус, –
колагына пышылдыйм.
Артымдагы зур
читлектә куркыныч хайван.
Һәрьякка куркыныч ис таралган.

Мин куркыныч хайваннарны яратам.
Алар белән бер читлектә
торырга гына теләмим.

Хайваннарның урыны рәшәткәләр
яки пыяла диварлар артында
яки дә аквариумда.

– Мин беркайчан да акуланы
кулга ияләштерергә теләмим, –
куянга пышылдыйм.
– Кыскасы, куркам.
Дөресен әйткәндә,
куркыныч хайваннардан куркам.
Аны син генә белеп тор.
Беркемгә дә сөйләмә.
Болай моннан соң
миңа беркем дә ышанмас.
Килештекме?

# Бүлем 22

Куян борынын тагын да тирәнрәккә
култыгыма тыга.

– Куркыныч түгел, –
дип аны пышылдап тынычландырам.
Мин үзем һич тә тыныч түгелмен.
Һич тә.
Бик куркам, уйларга да хәлем юк.
Алай булса да, бөтен вакыт уйлыйм.
Теләмәсәм дә, мием эшләп тора.
Барысын онытырга гына телим.
Бу начар төш кебек.

Миңа нишләргә кирәк, кинәттән беләм.
Читлек эчендә, җирдә, бер ботак ята.
Аның белән рәшәткәгә каксам,
бәлки кемдер ишетер.
Әмма ботак янына
курыкмыйча бара аламмы?
Теге куркыныч хайван,
һичшиксез, якында.

– Филип, сакланып, әкрен генә йөр, –
үз-үземә әйтәм.
Аяк очларына басып, ботакны барып алам.

Аннары ишек янына кире йөгерәм.
– Ахмак мангуст.
Барысы да синең гаебең, –
каты тавыш белән әйтәм.

Ботак белән рәшәткәгә
кага башлыйм.
Чаң! Чаң! Чаң!
Куян сискәнә.
Куркына да,
кочагымнан сикереп төшәргә тырыша.
Тагын бер тапкыр рәшәткәгә сугам.

Файдасы юк.
Тавыш җитәрлек көчле түгел.
Катырак тавышларга кирәк.
Зур читлектәге хайванны борчысам,
ни булыр?
– Бернинди дә хайван юк.
Үзең уйлап чыгарасың, Филип, –
үз-үземә әйтәм.

Тәвәккәл булырга кирәк.
Җитәрлек каты тавышласам,
кемдер мине ишетеп табар иде.

Рәшәткәгә катырак кагам.
Суккан саен куян калтырана.

Беркем дә килми.
Артык какмыйм,
чөнки кулым арыды.
Кулны алмаштырам.
Авырттырган кулымның
көче бер тапкырдан
артык сугарга җитми инде.
Утырып ял итәргә кирәк.

Шунда әллә нәрсә аркам
артында мырылдый.
Түбән, куркыныч тавыш.
Шул ук секунтта
Җилинең өрүен ишетәм.
Өрү тавышы еректан килә.
Аны кычкырып чакырырга кирәк.
Этләр яхшы ишетә.

– Җили, бире кил, – кычкырам.
Өрүен якынрактан ишетәм инде.
– Җили, монда, малай! –
кычкырып эндәшәм.

Ниһаять, этне күрәм.
Күземнән яшьләр ага башлый.
Хәлем җиңеләеп киткәнгә елыйм.
Берничә тамчы яшь куянның
өстенә дә тәгәрәп төшә.

# Бүлем 23

Җили дөньяның иң әйбәт эте.
Моннан соң беркайчан
да аңа ачуланмыйм.
София Җилине муен
бавыннан тотып,
артыннан йөгерә.

– София, мин монда, –
көчемнән килгән кадар кычкырам.

Җили ишек янына йөгереп килә дә,
өрә башлый.
Тышкы якта мангуст көтеп ята.
Җили аны куркыта.

Мангуст тагын сикерә дә
бии башлый.
Анысын белдем инде!
Ул ишек төбендә
бөтен вакыт куянны көтеп яткан.

Җили мангустны тотарга тырыша,
ләкин София муен бавын
каты тота, җибәрми.
София әкрен генә ишек янына килә.

– Һей Филип.
Ой сине, – әйтеп җибәрә.

Софияның күзләре
куркуыннан зурая.

Миңа туры карамый.
Аркам артында нидер күрә.
Бөтен тәнем боз кебек була.
Аркамнан суык
дулкыннар үтеп китә.

– Ой инде, –
София тагын әйтә дә,
аннары көлә.
– Курыкма!
Әкрен генә әйлән.
Куркыныч хәл түгел.
Аркаң артында юлбарыс баскан.

# Бүлем 24

Аякларым тотмый. Юлбарыс!

Кеше ашый торган куркыныч юлбарыс.
Ишеккә сөяләм.
Мин юлбарыс читлеге эчендә.
Якында куркыныч хайван бар
дип белдем бит.
Хайванның карашын аркамда сиздем,
ләкин юлбарыс булганын белмәдем.

София тыныч кына аңлата башлый:
‒ Юлбарыс эчтәге читлектә,
ә син тыштагысында.
Аның буе сиңа җитми.
Күрәсеңме, ул нинди матур? ‒ сорый.

Әкрен генә әйләнәм.
Әле юлбарысны күрәм.
Рәшәткә аркылы мине күзәтә.
Күзләре сары,
борыны киң.
Мырылдаганда озын үткен
тешләрен күрсәтә.

Юлбарыс бик якында.

Әгәр дә ике адым атласам,
мыегына тотына алам.
Юлбарысның тәпиләре куян кебек зур.
Юк, юлбарысның тәпиләре
куяннан зуррак.
София читлекнең тышкы ягындагы
белдерү тактасын укый.

– Бу себер юлбарысы, әйтә.
– Ул дөньяның иң зур мәче
хайваннарыннан санала.
Себер юлбарыслары арысланнан
зуррак, белдеңме?
Гадәттә юлбарысларның буе
ике-өч метрга хәтле.
Койрыгы белән өч метр озынлыкта була.

– Рәхмәт, – әйтәм.
– Җитте. Аңардан ис чыга.
– Әлбәттә, – София әйтә.
– Ул бит кечкенә читлектә тора.
Тышта, урманда ул азат яши,
исе чыкмый.

Юлбарыс куркыныч та,
шул ук вакытта матур да.
Авызы канга буялган.
Күзем канга төбәлә.

– Ул хәзер гына ашаган, –
София бармагы белән күрсәтә.

Еракта арттарак,
читлекнең бер читендә
сөякләр һәм бер зур кисәк ит ята.
Шуңа юлбарысны элегрәк сизмәдем.
Ул почмакта ашап яткан.



– Әле сине моннан
чыгарырга кирәк, –
София әйтә.
– Мин барып бер
караучы чакырам.
Курыкма.
Себер юлбарыслары
ифрат куркыныч,
әмма син булдырасың.
Синең һаман бәхетең бар.
Кечкенә песикәй белән
күңелле вакыт үткәр!

# Бүлем 25

София Җилине рәшәткәгә бәйләп куя.
Аннары үз юлы белән йөгереп китә.
Мин курыкмыйм.
Куркудан корыч кебек каттым.
Җавап кайтарырга да көчем юк.
Юлбарысны күзәтәм, ул мине күзәтә.
Юлбарыс мырылдый.
Тамагыннан каты мырылдау тавышы чыга.
Сары күзләрен йомгаламый да.
Башымны әйләндерәм, аңа карамыйм.
Аркам белән ишеккә сыланам.

Шунда юлбарыс авызын ача.
Зур авызы эчендә озын рәт тешләр күрәм.
Зур тәпиләре белән рәшәткәне
ничек кенә җиңел вата алыр иде.
Мине ашарга теләсә, аны да эшли ала.
Бәлки ул әле дә ач.

Җили читлекнең тышкы ягында
мангустка чиный да өрә.
Мангуст пудельнең әйләнәсендә бии
дә аны үртәп тора.
Ничек озак бер-беребезне күзәтеп тордык,
анысын белмим.

Бер ел дип тоела, юк, йөз ел.
Кинәт тавышлар ишетелә башлый.
София ишек янына йөгерә.
– Филип, хәлең ничек? –
тыны бетеп пуфылдый.
– Әле азат буласың. Менә ачкыч.
Караучы абый да Софияга ияреп йөгерә.
– Ой! – караучы әйтә.
– Ничек син анда читлек эченә эләктең?
Без бу кечкенә читлектән
юлбарысны ашатабыз.

Караучы ишекне ачкыч белән ача.
Читлектән куянны кочаклап,
абынып-абынып чыгам.
Мангуст тавышлый да, сикерә.
Куянны тешләргә тырыша, әмма
адашып минем беләгемне тешли.
– Әле җитте, – ачуланып кычкырам.

Җили мангуст артында өреп тора.
Ул Мангустны тешләргә тырыша.
Караучы читлекне бикли. София Җилине
тота. Ул өрүеннән туктый. Караучы
мангустны иңсәсеннән тотып күтәрә.
– Кара, син нинди шук, – мангустка әйтә.
– Минем белән бар. Бу качкынны кире
хуҗасына кайтарабыз.

# Бүлем 26

Мангустның фикере башка.
Ул киреләнә дә, караучының
кулыннан котыла.
Җилине тешләргә тырыша.
Караучы аны тагын тотып ала.
– Теге мангуст, – мин сүзгә керешәм.
– Ул мангуст түгел, – София сүземне бүлә.
– Ялгыш караганмын.
Ул кулга ияләшкән көзән.
– Ул тешли, – әйтәм.
– Уйный гына, – София әйтә.
– Уйнаганда тешли дә.
Ләкин синең кочагыңда нәрсә?
– Йорт куяны, – әйтәм. – Мангуст, юк,
көзән куянны тотарга тырышты.
Мин аны коткардым.

София кычкырып көлә.
– Филип, син каһарман, – әйтә.
– Көзәннәр куяннарны аулый.
Син аның ашын алдың.
Ул сиңа ачуланган, гаҗәп түгел.
Ул төшке ашын ашарга тели.
– Ничек син аны беләсең? – сорыйм.
– Пыш-пыш итеп тавышлады.

Көзән ачуланганда шулай тавышлый ул, –
София аңлата. – Куянны миңа күрсәтче.
Бик сөйкемле! Маңгай чәче дә бар, –
дип София әйтә дә көлә.

Кинәттән күзендә яшьләр.
Керфекләрен сирпеп ала.
– Син югалдың, – әйтә. – Аннары сине
юлбарыс белән читлектә таптым.
Һәм дә синең беләгең каный.
– Юлбарыс! – әйтәм.
Юлбарысны онытканмын.
Аны күрергә дип әйләнәм.
Ул рәшәткә янында яткан,
авызын ачкалап тора.

Карауччы көлә.
– Юлбарыс синең белән кызыксынды гына,
– әйтә. – Ул инде карт һәм дә аеруча
куркыныч та түгел. Алай булса да,
яхшы иттең, аңа тотынмадың.
Әгәр дә юлбарыс курыкса, көтмәгәндә
котырынырга мөмкин.
– Мин бит юлбарыска куркыныч түгел, –
каршы куям. – Ул миннән күп зуррак.
– Дөрес, син аңа куркыныч түгел, –
София мыгырдап әйтә.
– Әмма юлбарыс синнән куркырга тиеш.

# Бүлем 27

Бер тәбәнәк бина янында
төркем-төркем халык басып тора.
Анда берничә караучы һәм кафе
кунаклары җыелган. Караучыларның
берсе кочагымнан куянны ала.
Куянның тунына кан тамчылары төшкән.

Икенче караучы кечкенә читлек күтәргән.
Читлеккә көзәнне кертә.
София Җилине кулыннан җибәрә дә,
җиңе белән күзен сөртеп ала.
Җилинең каешын нык тота.
‒ Башмакларыңда кан, ‒ миңа әйтә.
Апаның тавышын ишетәм.
Яшел салам эшләпәсен күрәм. Ул халык
арасыннан этеп-төртеп яныма килә.
‒ Филип, шөкер, исәнсең, ‒
Бибинур апа кычкыра.
‒ Син нишләдең? Тилердеңме!

Мине кысып кочаклый.
Күлмәге һәм көмеш төсле чантасы
канга буяла, әмма ул аны сизми.
Эшләпәсе җиргә тәгәрәп төшә.
‒ Филип алтыным, ‒ апа дәвам итә.

– Мин бик кайгырдым. Әниең ни әйтер
инде? Ой, ярдәм! Һуштан китәм!

Җили аякларыма сикеренә.
Мин чүгәлим дә,
аны башыннан сыйпап алам.
Ул өрә, битемне ялап ала.
– Акыллы эт, мине таптың бит, – әйтәм.

Теге озын чәчле кыз көзән янына йөгерә.
Елаган. Битендә яшь эзләре.
– Китин! Сөйкемле Китинем, –
кыз кычкыра.
– Көзәннең исеме Китин, – караучы әйтә.
– Кызның исеме Катарина. Китин аныкы.
Китингә дару кадарга яки ветеринарга
күренергә кирәк вакытта
Катарина аны һаман бире китерә.

– Китингә энә кадарга идек тә,
ул югалды да куйды.
Бәхетебезгә, син аны таптың.
Көзәннәр азат булганда,
башка хайваннарга бик күп зарар
китерә алалар, – икенче караучы аңлата.
– Китин мине тапты, –
чыраемны сытып әйтәм.
– Без бер-беребезне яратмыйбыз.

# Бүлем 28

София бер кулъяулык чыгара да,
беләгемдәге канны сөртеп ала.
– Көзән ничә тапкыр
Филипне тешләгән, –
караучыга әйтә.
– Беләгенә көзәннең тешләвеннән
йогышлы микроблар керә аламы? –
София сорый.

– Юк. Көзәннең тешләре
бик үткен, – караучы әйтә.
– Ярага бернинди дә бактерия кермәс.
Ләкин алай булса да, Филип,
яраңны юарга һәм дә
беләгеңе бәйләргә кирәк.

– Куянны нишләтәсез? –
тынычсызланып сорыйм.
– Көзәнгә бирмисездер?
– Тунындагы канны юып алабыз да,
аны башка куяннар янына илтәбез, –
караучы әйтә.
– Ул каниннар тавында тора.
Бу куян бик еш үзенә
юл казып аннан кача.

Каниннар тавының тышкы ягындагы
маҗараларны ярата, – караучы аңлата.

– Мин куянны өемә ала аламмы? –
сорап карыйм.
– Читлектә тотсам, ул аннан кача алмый.
Монда анардан сезгә бары тик азап кына.

– Әниең куяннар яратмый, –
апа сүзне бүлә.
– Алар өйдәге бар нәрсәне чәйнәп бетерә.
Куяннар кабельләр ярата.
Компьютерыңның кабелен тешләп өзә ала.
Минем бер дустымның өй куяны бар…

– Биредә куян рәхәтрәк яши, –
караучы сүзне бүлә.
– Ул читлектә яшәргә күнмәгән.
Һәм дә ул башка куяннар
белән бергә яшәргә ярата.
– Кызганыч, – әйтәм.
– Мин бик-бик куян теләр идем.
Караучы куянны кочагына ала.
Катарина көзән читлеген күтәргән.
Ул безгә ияреп хайван караучыларның
бүлмәсенә керә.
Караучы ярамны юа да,
чүпрәк белән бәйләп куя.

Әле инде бик аз гына авырта.
Күлмәгемдәге канны да
юарга тырышам.
София миңа булыша.

Көзән мине күптапкыр тешләгән өчен
Катарина миннән гафу сорый.

– Китин уйнаганда мине дә тешли, –
Катарина әйтә.

Беләген күрсәтә.
Беләгендә көзәннең үткен
тешләреннән калган
күп эзләр бар.
Аннары Катарина тынычсызлана.
Маңгае җыерыла.

– Эт тешләгәннән Китингә
бернинди дә хасталык йокмастыр? –
дип караучыдан сорый.
– Уйламыйм. Ләкин Китингә берни
булмаска укол кадый алабыз.

Караучы апама таба борыла.
– Нигә сез хайван бакчасына
эт китердегез? – караучы сорый.
– Ул катыгый тыелган.

# Бүлем 29

Бибинур апаның йөзе кызара.
– Бу бит бик бәләкәй, – әйтә.
– Били бернинди дә усаллык эшләми.
– Көзәнне тешләп үтерә ала иде, – карауч әйтә.
– Пудельләр оста аучылар.

Апа тагын да күбрәк кызарына.
– Мин уйладым… – сөйли башлый, ләкин караучы аның сүзен бүлә:
– Этләр биредәге хайваннарга куркыныч хасталыклар китерә алалар. Биредәге хайваннарның да этләр өчен куркыныч хасталыклары була ала. Шуның өчен монда этләр китерергә ярамый. Безгә хайваннарыбызны да, этләребезне дә эпидемияләрдән сакларга кирәк.
– Аны мин белмәдем, – апа мыгырдана.

Бер мизгел әкрен тора.
Аннары коты очып кычкыра:
– Били хасталанган булса?
Аны хәзер үк ветеринарга күрсәтергә кирәк.

‒ Иң башта Филипнең беләгел
хастаханәгә барып күрсәтергә кирәк, ‒
караучы әйтә.
‒ Аның беләген яхшы дәваларга кирәк.
Аннары этегез белән ветеринарга
бара аласыз.
‒ Филипнең әнисенә шалтыратырга
кирәктер, ‒ София әйтә.
‒ Мин шалтыратам, ‒ Бибинур апа әйтә.
Апа Җилине тагын чантасына тыга да,
зипперен яба.
‒ Әкрен утыр, ‒ Җилигә кискен әйтә.
‒ Сиңа котыру авыруы яки башка
куркыныч хасталык эләгергә мөмкин.

Апа әнигә эшкә шалтырата,
ләкин ни булганын аңлатмый.
Бераз соңлыйбыз гына, әйтә.
Апа эшне акыллы башкарды.
Аның өчен рәхмәт укыйм.
Әлегә мин әнигә барысын да
аңлатырга теләмим.
Минем канлы киемнәремне күргәч,
әлбәттә, әни куркына.
‒ Әниең синең белән сөйләшергә тели, ‒
Бибинур апа әйтә. Телефонны миңа суза.
Өч мәртәбә йотынам да,
һей дип сәламлим.

# Бүлем 30

Әлбттә, әни миңа ачулы.
Һич тә нервалы түгел.
Арыган гына.
‒ Филип, тагын аздыңмы? ‒
әни тирән сулап әйтә.

‒ Бераз шулайрак булды шул.
Безгә хастаханәгә барырга кирәк.
Берни дә булмаска.
Куркыныч түгел.
Минем хәлем яхшы, ‒ әйтәм.

Әни тагын тирән сулап ала.
‒ Сиңа һаман ни булса була.
Өйгә кайткач аңлатырсың.
Сезне хастаханәдән килеп алыйммы?
Яки әтиеңә шалтыратыйммы? ‒ сорый.
‒ Юк, кирәкми. Такси алалабыз.
Сау бул! ‒ диям.
Тагын ни булса сорарга өлгермәсен дип
телефонны тиз генә ябам.

Һастаханәгә барганда Софияга әйтәм:
‒ Мине коткарганың өчен сиңа рәхмәт.
Сиңа һәм Җилигә.

Син бик батыр.
Юлбарыстан да курыкмадың.
Хайваннар турында да күп беләсең.
– Син дә батыр, куянны коткардың, –
София җитдиләнеп әйтә.
– Болай көзән аны ашап куйган булыр иде.

– Зоопаркка тагын
барырга кирәк, – Софияга әйтәм.
– Юлбарысны һәм арысланны рәсемгә
төшерергә өлгермәдем.
Ләкин ак барсны шәп рәсемгә төшердем.
– Һәрхәлдә иртәгә бармыйсыз, –
апа кычкыра.
– Әлегә, миңа калса,
хайван бакчасы җитте.

– Иртәгә аквариумга баралабыз, –
тәклиф итәм.
– Әлбәттә, – София әйтә.
– Белдеңме, юлбарыс акуланың
тешләре гомере буе үсә?
– Һәм дә ифрат үткеннәр, – өстим.
Икебез дә көләбез.
София көлгәндә сөйкемлегә охшый.

– Сез ике ахмак, – Бибинур апа әйтә.
– Һуштан китәм!



**Филип куркыныч хайваннарны ярата. Ул хайван бакчасында өй куянының гомерен коткара.**

**Филип бер читлеккә ябылып кала. Читлектә бик куркыныч хайван тора.**

**Филип аннан ничек котыла?**

җиңел тел

978-952-7334-81-2

ISBN 978-952-7334-81-2 (кәгазь китап)
ISBN 978-952-7334-82-9 (е-китап, PDF)

**aybagar.eu ∘ bokpil.eu**